**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

16.11.2020 Балык Бистәсе штп. №232пи

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 1 июнендәге 104п номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының "Спорт мәктәбе" муниципаль бюджет учреждениесендә эшләүче яшь белгечләргә акчалата түләүләрне гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан Балык Бистәсе муниципаль районы бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Норматив хокукый актны гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, "Татарстан Республикасының спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы физкультура спорт оешмаларында эшләүче яшь белгечләргә акчалата түләүләр билгеләү турында" Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 31 октябрендәге 979 номерлы Күрсәтмәсенә таянып КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 1 июнендәге 104п номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының "Спорт мәктәбе" муниципаль бюджет учреждениесендә эшләүче яшь белгечләргә акчалата түләүләрне гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан Балык Бистәсе муниципаль районы бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенә (алга таба – Тәртип) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Тәртип аталышындагы "Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының "Спорт мәктәбе" муниципаль бюджет учреждениесендә эшләүче" сүзләрен "Татарстан Республикасының спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы физкультура спорт оешмаларында эшләүче" сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм

http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының “Яшьләр сәясәте, спорт һәм туризм буенча бүлеге” МКУ башлыгы И.З. Шакировка йөкләргә.

Җитәкче Р.Л. Исланов